**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «24» декабреннән № 350

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә түләүдән азат итү шартлары турында» 2020 ел, 8 май, 119 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә азат итү шартларына үзгәрешләр кертү турында»

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 маендагы 1296-р номерлы күрсәтмәсе белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертелде, шул күрсәтмәләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.04.2020 ел, № 820-р һәм № 821-р күрсәтмәләре чыгарылды, шуларга таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә азат итү шартлары турында " 2020 ел, 8 май, 119 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа

Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә азат итү шартларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә түләүдән азат итү шартлары турында» гы 8.05.2020 ел, № 119 карарына кушымтаның 1 пунктындагы «Бердәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары реестрына кертелгән оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләреннән соң «үзмәшгуль гражданнар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмати- телекоммуникацион челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда htt:/pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яисә өлешчә түләүдән азат итүне хәл иткәндә, әлеге карарга таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.Р. Фәсахов